**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.06.2014 № 333

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2014 елның 22 сентябрендә теркәлде, №2435

“Һәлак булган (үлгән) хәрби хезмәткәрләрнең
гаиләләре әгъзаларына таныклык бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентын
раслау турында” 05.07.2012 ел, №513
Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгы
боерыгы белән расланган Һәлак
булган (үлгән) хәрби хезмәткәрләрнең
гаиләләре әгъзаларына таныклык бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

“Һәлак булган (үлгән) сугыш инвалиды, Бөек Ватан сугышында катнашучы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераны гаиләсе әгъзасының таныклыгы турында” 20.06.2013 ел, №519 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарының гамәлгә керүенә бәйле рәвештә, боерык бирәм:

“Һәлак булган (үлгән) хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләре әгъзаларына таныклык бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 05.07.2012 ел, №513 Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган Һәлак булган (үлгән) хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләре әгъзаларына таныклык бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Һәлак булган (үлгән) сугыш инвалиды, Бөек Ватан сугышында катнашучы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераны гаиләсе әгъзасының таныклыгы турында” 20июнь, 2013 ел, №519 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә (алга таба - №519 карар) (“Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 01.07.2013, №26, 3341 ст.);”;

1 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 1.5 пунктны өстәргә:

“1.5. Бу Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) төшенчәсе дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны аңлата (27 июль, 2010 ел, №210-ФЗ Федераль Законның 2 статьясындагы 1 пункты). Гаризаның тәкъдим ителә торган формасы Регламентка №1 кушымтада китерелгән .”;

2 бүлектә:

Атаманы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты”;

“Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында (2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.Социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклык бирү хакында гариза (Бу Регламентка №1 кушымта).”

2. 3х4 үлчәмендә фотосурәт.

3. Документлар күчермәләре:

һәлак булган (үлгән) затның хәрби хезмәт үткәнлеге яки сугыш хәрәкәтләрендә катнашканлыгы турында;

һәлак булган (үлгән) зат белән туганлык мөнәсәбәтләрен раслый торган.

Бу регламентның 1.2 пунктындагы 2 абзацында күрсәтелгән гражданнар өстәмә тапшыра:

эшкә сәләтсезлекне раслаучы документлар күчермәләре;

һәлак булган (үлгән) кешенең иждивениесендә булганлыкны раслый торган суд карары күчермәсе.

Бу регламентның 1.2 пунктындагы 6 абзацында күрсәтелгән гражданнар өстәмә тапшыра:

18 яшьтән зуррак балага 18 яшькә җиткәнче инвалидлык билгеләнү турында медицина-социаль экспертиза бюросыннан белешмә күчермәсе;

23 яшькә җитмәгән баланың мәгариф учежденеиеләрендә көндезге формада укуы турында мәгариф учреждениесеннән белешмә.

Мөрәҗәгать итүче документлар һәм белешмәләрне тиешле оешмалардан турыдан-туры ала, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә.

Мөрәҗәгать итүче гариза белән мөрәҗәгать иткәндә паспорт (аны алыштыручы документ) тапшыра. Дәүләт хезмәтен алучының вәкиле дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә вәкаләтләрен раслаучы документлар тапшыра.

Документлар күчермәләре, Россия Федерациясе законы нигезендә расланылмаган очракта, Идарә (бүлек) белгече тарафыннан раслана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә, аңа кушып бирелә торган документлар күчермәләре, паспорт күчермәсен яки аны алыштыручы документ күчермәсен кертеп, закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә расланган булырга тиеш.”;

“Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында 2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Туендыручысын югалту очрагы буенча пенсия алуга хокук турында мәгълүматлардан торган документ (Россия Федерациясе Пенсия фондының Ттатарстан Республикасындагы бүлегендә).

Балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматлардан, үлем-китемне дәүләт теркәвенә алу (ЗАГС органнарында) турында мәгълүматлардан торган документлар.

Әлеге мәгълүматлардан торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры алынырга мөмкин, мөмкинлек булганда – электрон рәвештә.”;

“Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында 2.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып тора:

Документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;

дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан регламентны бозу очраклары (нигезле шикаятьләр) булу-булмау ( мондый очракларның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Министрлыкның вазыйфаи затларының гомуми санына карата нисбәте).

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләре булып тора:

территориаль социаль яклау органының җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашкан булуы;

белгечләрнең кирәкле санда булуы, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү өчен кирәкле бүлмәләрнең тиешле санда булуы;

Министрлыкның мәгълүмати стендларында, “Интернет” челтәрендәге мәгълүмати ресурсларында, Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүматның булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге.”;

“Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында 2.16 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

“Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны кертеп, МФЦ аша хәл ителми.”;

3 бүлектә:

атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Административ процедуралар составы, аларны үтәү эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон

рәвештә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре”;

3.1.1 пунктның 1 пунктчасына “, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм итү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан” дигән сүзләр өстәргә;

3.2 пунктның икенче абзацында “дәүләт хезмәте күрсәтү” дигән сүзләрдән соң “һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм итә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан” дигән сүзләр өстәргә;

3.3.3 пунктка түбәндәге эчтәлектәге өченче абзац өстәргә:

“2013 елның 23 октябренә кадәр туган балаларның тууын ЗАГС органында дәүләт теркәвенә алу турында (2015 елның 1 гыйнварыннан сорала).”;

3.3.4, 3.3.5 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Идарә (бүлек) белгече 2013 елның 23 октябреннән соң туган балаларның тууын ЗАГС органында дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматлар, үлем-китемне дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматлар ала.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедуралар гариза алынган көнне хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүматлар алу.

3.3.5. Идарә (бүлек) белгече бу Регламентның 3.3.3 һәм 3.3.4 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматлар һәм мөрәҗәгатъ итүче тапшырган документлар нигезендә бу Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләрнең булу-булмавын тикшерә.

Идарә (бүлек) белгече, бу регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр булмаган очракта:

мөрәҗәгать итүче гариза һәм документларны электрон рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша тапшырганда – мөрәҗәгать итүчегә бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны (гаризадан тыш) кәгазьдә тапшыру зарурилыгы турында белдерү кәгазе җибәрә;

таныклык бланкын рәсмиләштерә;

таныклык бланкын Идарә (бүлек) җитәкчесенә имза салдыруга җибәрә.

Гариза һәм документлар электрон рәвештә алынган очракта Мөрәҗәгать итүче бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырганнан соң таныклык бланкы рәсмиләштерелә.

Идарә (бүлек) белгече, бу Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү урында гаризада күрсәтелгән ысул белән (хат, телефон, смс-хәбәр, электрон почта аша) таныклык бирүдән баш тарту турында мөрәҗәгать итүчегә җиткерә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедуралар запросларга җаваплар алынганнан соң ике көн эчендә хәл ителә, әмма гариза теркәлгәннән соң җиде көннән дә соңга калмыйча.

Процедуралар нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә таныклык бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе җибәрү, таныклык бланкын рәсмиләштерү.";

3 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге яңа 3.3.6 пунктны өстәргә:

"3.3.6. Идарә (бүлек) белгече документларны карап тикшергәннән соң рәсмиләштерелгән таныклык бланкына имза сала һәм аны Идарә (бүлек) белгеченә җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура рәсмиләштерелгән таныклык бланкы имза салуга җибәрелгәннән соң бер көн эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: таныклык бланкын рәсмиләштереп, Идарә (бүлек) җитәкчесеннән имза салдырту.";

3.3.6 пунктны 3.3.7 пункт итеп исәпләргә;

3 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 3.4 пунктын өстәргә:

"3.4. Дәүләт хезмәте МФЦ аша күрсәтелми.".

4 бүлекнең 4.3 пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү Идарәнең (бүлек) дәүләт хезмәте күрсәтүдәге эшчәнлегенең хәбәрдарлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләр) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу юлы белән хәл ителә.";

5 бүлектә:

атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының һәм дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе";

5.2 пунктның икенче абзацында "почта аша" дигән сүзләрдән соң "МФЦ аша," дигән сүзләр өстәргә;

5 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 5.8 пунктны өстәргә:

"5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи зат материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.";

Регламентка кушымтаны (белешмә) яңа редакциядә (кушымта итеп бирелә) бәян итәргә.

“Һәлак булган (үлгән)
хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләре
әгъзаларына танылык бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына кушымта
(белешмә)

**Һәлак булган (үлгән) хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләре әгъзаларына таныклык бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар**

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органнары

| Территориаль орган атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Әгерҗе муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85551)<br>2-10-86<br>2-26-39 | 422230, Әгерҗе ш.,<br>К.Маркс ур., 8 й.,<br>Agreez.Usz@tatar.ru |
| Азнакай муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85592)<br>7-25-10<br>7-14-25 | 423300, Азнакай,<br>Болгар ур., 9 й.<br>Usz.Azn@tatar.ru |
| Аксубай муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84344)<br>2-73-68<br>2-82-75 | 423060, Аксубай ш.т.б.,<br>Ленин ур., 8 й.<br>Usz.Aksubaevo@tatar.ru |
| Актаныш муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85552)<br>3-11-46<br>3-12-81 | 423740, Актаныш ав.,<br>Юбилей ур., 45 й.<br>Usz.Aktanysh@tatar.ru |
| Алексеевск муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84341)<br>2-41-40<br>2-46-46 | 422900, Алексеевск ш.т.б.,<br>Казаков ур., 8 й.<br>Usz.Alekseevsk@tatar.ru |
| Әлки муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84346)<br>2-08-90<br>2-08-91 | 422870, Базарлы Матак ав.,<br>Ленин ур., 9 й.<br>Usz.Alkeevo@tatar.ru |
| Әлмәт муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (8553)<br>32-45-50 | 423452, Әлмәт ш.,<br>8 март ур., 21а й.<br>Usz.Almet@tatar.ru |
| Апас муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84376)<br>2-11-84<br>2-10-81 | 422350, Апас ав.,<br>Шоссе ур., 5 й.<br>Usz.Apastovo@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Арча муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84366)<br>3-13-53<br>3-13-33 | 422000, Арча ш.,<br>Банк ур., 6в й.<br>Usz.Arsk@tatar.ru |
| Әтнә муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84369)<br>2-16-60<br>2-16-57 | 422750, Олы Әтнә ав.,<br>Октябрь ур., 9 й.<br>Usz.Atnya@tatar.ru |
| Баулы муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85569)<br>5-10-50<br>5-66-81 | 423930, Баулы ш.,<br>Җиңү мәйданы, 4 й.<br>usz.bavly@tatar.ru |
| Балтач муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84368)<br>2-44-78 | 422250, Балтач ав.,<br>Һ.Такташ ур., 3а й.<br>Usz.Baltasi@tatar.ru |
| Бөгелмә муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85594)<br>4-20-05<br>4-26-64 | 423230, Бөгелмә ш.,<br>Совет ур., 56 й.<br>Usz.Bugulma@tatar.ru |
| Буа муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84374)<br>3-32-10<br>3-35-35<br>3-17-03<br>3-55-29 | 422430, Буа ш.,<br>Ленин ур., 52 й.<br>Usz.Buinsk@tatar.ru |
| Югары Ослан муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84379)<br>2-17-57<br>2-13-01 | 422570, Югары Ослан ав.,<br>Медгородок ур.<br>Usz.V-uslon@tatar.ru |
| Биектау муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84365)<br>2-32-43 | 422700, Биектау ст. т.юлчылар б.,<br>Профсоюз ур., 1а й.<br>Usz.Vgora@tatar.ru |
| Чүпрәле муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84375)<br>2-38-07<br>2-31-52 | 422470, Иске Чүпрәле ав.,<br>Үзәк ур., 15 й.<br>Drozh.Usz@tatar.ru |
| Алабуга муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85557)<br>7-51-55<br>7-87-86 | 423600, Алабуга ш.,<br>Спас ур., 5 й.<br>Usz.Elabuga@tatar.ru |
| Зәй муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85558)<br>7-10-64<br>3-43-59 | 423520, Зәй ш.,<br>Крупская ур., 6 й.<br>Usz.Zainsk@tatar.ru |
| Зеленодол муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84371)<br>5-58-80<br>5-79-90 | 422540, Зеленодол ш.,<br>Ленин ур., 25 й.<br>Usz.Zeldol@tatar.ru |
| Кайбыч муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84370)<br>2-14-07<br>2-11-13 | 422330, Олы Кайбыч ав.,<br>Кояшлы бульвар, 7 й.<br>Usz.Kaybicy@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Кама тамагы муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84377)<br>2-15-57<br>2-12-45 | 422820, Кама Тамагы ш.т.б.,<br>К.Маркс ур., 2 й.<br>Usz.K-uste@tatar.ru |
| Кукмара муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84364)<br>2-84-76<br>2-64-65 | 422110, Кукмара ш.т.б.<br>Ворошилов ур., 44 й.<br>Usz.Kukmor@tatar.ru |
| Лаеш муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84378)<br>2-47-31<br>2-49-70 | 422610, Лаеш ш.,<br>Беренче Май ур., 35 й.<br>Osz.Laishevo@tatar.ru |
| Лениногорск муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85595)<br>5-07-51<br>6-02-26 | 423250, Лениногорск ш.,<br>Горький ур., 21 й.<br>Usz.Leninogorsk@tatar.ru |
| Мамадыш муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85563)<br>3-12-36 | 422190, Мамадыш ш.,<br>Совет ур., 10 й.<br>Usz.Mamadysh@tatar.ru |
| Менделеев муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85549)<br>2-23-00 | 423650, Менделеев ш.,<br>Бурмистров ур., 7а й.<br>Usz.Mendeleev@tatar.ru |
| Минзәлә муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85555)<br>3-26-59<br>3-19-77<br>3-14-52 | 423700, Минзәлә ш.,<br>Ленин ур., 80 й.<br>Usz.Menzelinsk@tatar.ru |
| Мөслим муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85556)<br>2-57-37 | 423970, Мөслим ав.,<br>Пушкин ур., 47 й.<br>Usz.Muslyumovo@tatar.ru |
| “Чаллы шәһәре” муниципаль берәмлегендә социаль яклау идарәсе | (8552)<br>34-48-48<br>58-71-52 | 423805, Чаллы ш.,<br>Х.Туфан проспекты, 23 й.<br>Usz.Chelny@tatar.ru |
| Түбән Кама муниципаль районында социаль яклау идарәсе | (8555)<br>45-39-20<br>45-43-86<br>45-43-89 | 423570, Түбән Кама ш.,<br>Тынычлык проспекты, 60 й.<br>usznizhnekamck@tatar.ru |
| Яңа Чишмә муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84348)<br>2-20-15 | 423190, Яңа Чишмә ав.,<br>Совет ур., 80 й.<br>Usz.Novoshesh@tatar.ru |
| Нурлат муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84345)<br>2-06-62<br>2-06-55<br>2-39-88 | 423040, Нурлат ш., Мәктәп ур., 8 й.<br>Usz.Nurlat@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Питрәч муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84367)<br>3-06-68<br>3-06-72 | 422770, Питрәч ав.,<br>Совет ур., 20 й.<br>Usz.Pitriash@tatar.ru |
| Балык Бистәсе муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84361)<br>2-11-57<br>2-39-62 | 422650, Балык бистәсе ав.,<br>Завод ур., 6а й.<br>Usz.R-sloboda@tatar.ru |
| Саба муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84362)<br>2-34-37 | 422060, Байлар Сабасы ш.т.б.,<br>Тукай ур., 87 й.<br>Usz.Saby@tatar.ru |
| Сарман муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85559)<br>2-45-72<br>2-49-87 | 423350, Сарман ав.,<br>Куйбышев ур., 36 й.<br>Usz.Sarmanovo@tatar.ru |
| Спас муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84347)<br>3-08-81<br>3-00-00<br>3-08-98 | 422840, Болгар ш.,<br>Хирург Шеронов ур., 13 й.<br>Usz.Bolgar@tatar.ru |
| Тәтеш муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84373)<br>2-62-31 | 422370, Тәтеш,<br>Ленин ур., 114 й.<br>Usz.Tetyushi@tatar.ru |
| Тукай муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (8552)<br>70-00-57 | 423807, Чаллы ш.,<br>М.Җәлил проспекты, 46 й.<br>Usz.Tukaev@tatar.ru |
| Теләче муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84360)<br>2-13-41 | 422080, Теләче ав.,<br>Большая Нагорная ур., 5 й.<br>Usz.Tulachi@tatar.ru |
| Чирмешән муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84396)<br>2-57-05<br>2-50-94 | 423100, Чирмешән ав.,<br>Гагарин ур., 7 й.<br>Usz.Cheremshan@tatar.ru |
| Чистай муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84342)<br>5-55-73<br>5-11-50 | 422980, Чистай ш.,<br>Урицкий ур., 45 й.<br>Usz.Chistopol@tatar.ru |
| Ютазы муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85593)<br>2-21-43<br>2-82-91<br>2-84-41 | 423950, Урыссу ш.т.б.,<br>Пушкин ур., 105/1 й.<br>Usz.Utazy@tatar.ru |
| Казан. ш. Авиатөзелеш районы социаль яклау бүлеге | 571-58-00 | 420036 Казан ш., Тимирязев ур., 8 й.<br>Usz.Avia@tatar.ru |
| Казан. ш. Вахитов районы социаль яклау бүлеге | 238-10-55 | 420043 Казан ш., Вишневский ур., 10 й.Usz.Vahit@tatar.ru |
| Казан. ш. Киров районы социаль яклау бүлеге | 554-47-80 | 420102 Казан ш., Г.Баруди ур., 5 й.<br>Usz. Kirov@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Казан. ш. Мәскәү районы социаль яклау бүлеге | 544-89-94 | 420095 Казан ш., Блюхер ур., 81а й Usz.Moskov@tatar.ru |
| Казан. ш. Яңа Савин районы социаль яклау бүлеге | 523-75-82 | 420044 Казан ш., Ямашев пр., 37 й Usz.Novosavin@tatar.ru |
| Казан. ш. Идел буе районы социаль яклау бүлеге | 224-04-20 | 420059 Казан ш., Р. Зорге ур., 39 й. Usz.Priv@tatar.ru |
| Казан. ш. Совет районы социаль яклау бүлеге | 273-18-06 | 420037 Казан ш., Г.Кутуй ур., 33 й. Usz.SovOR@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-02 | mtsz@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чаралары методологиясе бүлеге начальнигы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Күрсәтелә торган социаль ярдәм чараларына функциональ аудит бүлеге начальнигы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru |

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Социаль үсеш идарәсе начальнигы | 264-77-29 | pisma@tatar.ru |

**Министр** **А.Р.Шәфигуллин**